СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2019ел с. Сарманово № 173

Сарман муниципаль районы Советының 2012 елның 28 маендагы 65 номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында Карар кабул итү тәртибен раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» Сарман муниципаль районы Советының 2012 елның 28 маендагы 65 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлек 3 пунктта "дача төзелеше," сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (pravo.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Элеге караның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин